**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ВЕРХНЕКАМЕНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
улица Дружба, дом 1а, село Верхняя Каменка,
423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**
Дружба урамы, 1а йорт, Югары Кәминкә авылы,
423108

тел./факс (84396) 2-34-60/2-34-16 email: Vkam.Cmn2@tatar.ru

№ 77 от 12 март 2018 ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Югары Кәминкә
авыл җирлеге Советының 18.11.2013 ел
№56 санлы “Җир салымы турында”
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 нче бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы прокурорының 09.02.2018 №166-р санлы протестын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының 18.11.2013 елдан №56 санлы “Җир салымы турында” карарының (14.11.2014 № 69 кертелгән үзгәрешләр белән) “Салым базасын киметергә мөмкинлек бирүче документларны тапшыру тәртибе һәм сроклары” исемле 6 нчы статьясын яңа басмада бәян итәргә:

“Салым түләчеләр – салым һәм җыюлар турындагы закон тарафыннан куелган салым ташламаларына, шул исәптән салым чигерүгә хокуклы физик затлар үзләре сайлаган салым органына салым ташламасы бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым түләүче аның салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырыга хокуклы. Салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслау Россия Федерациясе Салым кодексының 361.1 статьясының 3 нче пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Салым түләчеләр - шәхси эшмәкәр булган физик затлар, салым декларациясен бирү өчен куелган срокларда.

2 Әлеге карар 2018 нче елның 1 нче январеннән соң барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә тарала.

3. Әлеге карарны нтернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карарны үтәүне контрольдә тотуны үз өстемә алам.

"Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге”
Муниципаль берәмлеге Башлыгы К.М.Гилязов